Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 3 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган әгъзасы урынына Иҗтимагый палата составына вәкил күрсәткәндә Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма үз вәкилен Иҗтимагый палата составына кертү турындагы гаризасын Иҗтимагый палата әгъзалыгына кандидатлар күрсәтү турындагы мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре туктатылган әгъзасын раслаган органга җибәрә.";

2) 9 статьяның 1 өлешендә "ике" сүзен "өч" сүзенә алмаштырырга;

3) 10 статьяның 1 өлешендә ", Татарстан Республикасында даими яшәүче" сүзләрен төшереп калдырырга;

22



4) 13 статьяның 3 өлешендә "Иҗтимагый палата Советы карары белән" сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 21 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршында һәм муниципаль берәмлекләрдә төзелгән иҗтимагый советларга мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтү.";

6) 22 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына шушы органнар компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гарызнамәләр җибәрергә. Иҗтимагый палата гарызнамәләре аның әлеге Законның 3 статьясында күрсәтелгән максатларына һәм бурычларына туры килергә тиеш. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары Иҗтимагый палата гарызнамәләре буенча аның үз вәкаләтләрен башкару өчен аңа кирәкле белешмәләрне, дәүләт серен һәм федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән тыш, бирергә тиеш, шул исәптән документлар һәм материаллар рәвешендә дә. Иҗтимагый палата гарызнамәсе җибәрелгән вазыйфаи зат, гарызнамә алынган көннән 30 көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый палата билгели торган аерым очракларда 14 көннән дә соңга калмыйча, аңа җавап бирергә тиеш. Җавапка гарызнамә җибәрелгән вазыйфаи зат йә аның вазыйфаларын башкаручы зат имза салырга тиеш;";

7) 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 22$^{1}$ статья өстәргә:

"22$^{1}$ статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы һәм муниципаль берәмлекләрдәге иҗтимагый советлар эшендә Иҗтимагый палата әгъзаларының катнашуы**

1. Иҗтимагый палата Советы иҗтимагый совет төзү тәкъдиме белән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм җирле үзидарә органы җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары каршындагы иҗтимагый советларны төзү тәртибе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, ә муниципаль берәмлекләрдә уставлар һәм (яисә) башка муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

3. Иҗтимагый советлар эшендә Иҗтимагый палата әгъзалары да катнаша ала.";

8) 24 статьяда:

3 өлештә "2 – 4 пунктларда" сүзләрен төшереп калдырырга;

4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Татарстан Республикасы законнары проектлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә Иҗтимагый палатага җибәрелә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан

23

Республикасы министрлыкларының һәм ведомстволарының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган Гавами өстенлекләр реестрына кертелгән чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар проектлары, экспертиза үткәрү өчен кирәкле документлар һәм материаллар белән бергә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан Иҗтимагый палатага җибәрелә. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актлары проектлары Иҗтимагый палатага Иҗтимагый палата гарызнамәсе буенча җибәрелә.";

9) 25 статьяның 4 өлешендә "Иҗтимагый палата әгъзалары" сүзләре алдыннан "Иҗтимагый палата Советы вәкаләт биргән" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы өченче составының вәкаләтләре срогы "Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында" 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы (әлеге Закон редакциясендә) нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2009 елның 18 декабре
№ 66-ТРЗ